**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 июль № 527

г. Казань

2016/2017 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында

2016/2017 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2016 елның 15 сентябренә кадәр гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын 2016/2017 елның кышкы чорына әзерлек чаралары комплексын эшләүне оештырырга;

2016 елның 1 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм башка мәнфәгатьле министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә «Буран» оператив планына төзәтмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең кар көртләре, автомобиль һәлакәтләре нәтиҗәсендә тоткарланып калган затларга үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү буенча гамәлләргә әзерлеген тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2016 елның 1 октябренә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту буенча муниципаль контрактлар төзүне;

юл-коммуналь хезмәтләрне кышкы шартларда эшләүгә әзерләүне оештыруны һәм шәһәрләрнең һәм районнарның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле урам-юл челтәрен һәм җирле автомобиль юлларын карап тоту өчен кар чистарту техникасын беркетүне гамәлгә ашыруны;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив планнарга төзәтмәләр кертүне;

сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре җитәкчеләре белән берлектә, 2016/2017 елның кышкы чорында куркыныч метеорологик хәлләр килеп чыкканда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында калган затларны кайнар аш һәм азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнә торган предприятиеләрне билгеләүне.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсенә – 2016/2017 елның кышкы чорында табигый гидрометеорология күренешләре һәм атмосфера процесслары үзгәрү фаразы турында Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына үз вакытында мәгълүмат кертүне;

Казан гарнизоны башлыгына – законнар нигезендә республика территориясендә «Буран» планы кертелгәндә Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган автомобиль юлларында кар көртләрен чистарту һәм кар баскан юлларда тоткарланып калган кешеләрне коткару өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби уку йортлары һәм хәрби частьләре шәхси составын, махсус һәм автомобиль техникасын бирүне күздә тотуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә – автомобиль юлларын карап тотуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы бүлекчәләренә кар көртләре өелгән урыннарга юл техникасы һәм махсус техника керүне, шулай ук кешеләрнең, шул исәптән балаларның, зур төркемнәрен алып баручы автомобиль колонналарын һәм махсуслаштырылган күчмә җәмәгать туклануы һәм сәүдә формированиеләрен, зыян күргәннәргә медицина ярдәме күрсәтүче төркемнәрне транспорт вакытлыча тупланган урыннарга үткәрүне оештыруда ярдәм итүне;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлына һәм «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Куйбышев тимер юлына – Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган тимер юлларда кар көртләрен бетерү өчен эшчеләр һәм техника бирү турында шартнамәләр төзүне.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015/2016 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2015 ел, 28 август, 628 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\527.doc